ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 март 2019ел № 1144

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2018 елның 18 июлендәге 4000 нче, 2018 елның 27 июлендәге 4226 нчы, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 нчы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә:

- 1 пунктта «Программа» сүзен «ярдәмче программа» сүзләренә алмаштырырга;

- 6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Күп фатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру эшләрен килешенү.»;

- 10 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«10. Бүлмәне торак бүлмә, торак бүлмәне яшәү өчен яраксыз, күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки яңартып төзелергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану.»;

-11 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11. Торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү.»;

- 20 пунктны төшереп калдырырга;

- 39 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«39. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү.»;

- 44 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«44. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир участокларын милеккә бушлай бирү (тапшыру).»;

- 46, 49 пунктларны төшереп калдырырга;

- 51 пунктта «дача» сүзен төшереп калдырырга;

- 72 пунктны төшереп калдырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 76-85 пунктлар белән тулыландырырга:

«76. Муниципаль белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру турында мәгълүмат бирү.

77. Җир участогын территорияне комплекслы үзләштерү өчен бирү.

78. Планлаштырылган төзелеш яки яңартып төзү турындагы белдерү кәгазендә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир участогында урнаштыру рөхсәт ителү (рөхсәт ителмәү) турында белдерү кәгазе җибәрү.

79. Төзелгән яки яңартып төзелгән шәхси торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү.

80. Җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү.

81. Социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүләре буенча торак бүлмәләр бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу.

82. Чит җир участогыннан чикле файдалану хокукы (җәмәгать сервитуты) бирү.

83. Капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең, яңартып төзүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү.

84. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килешенү.

85. Каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы) турындагы мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегендә:

- 25 пунктны «бүлеге» сүзеннән соң «1.1 һәм» сүзләре белән тулыландырырга;

- түбәндәге эчтәлектәге 26-28 пунктлар белән тулыландырырга:

«26. Аерылышуны дәүләт теркәвенә алу.

27. Язылышуны дәүләт теркәвенә алу.

28. Гражданнар хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклык (белешмә) бирү.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев